


21 июльдә РМ Дәvләт Жыелышы депутаты А.А.Болдырев, «Чәчәкләр доньясы» генераль директоры «Бердәм Россия» жирле ижтимагый кабул итv партиясендә гражданнарны чираттагы кабул итv vткәргән.
Кадошкино районы Насакан Потьма авылында гомер итvче Рәшит Исмаил улы Асаинов А.А.Болдыревка сорау белән морәжәгать иткән.       Кечкенә генә Насакан Потьма авылы халкы исеменнән ул авыл халкын транспорт белән тәэмин итv мәсьәләсен хәл итvдә ярдәм сораган. Эш шунда ки, даими (постоянно) 20 кеше яши торган авылга, кvбесенчә пенсия яшендәгеләргә, авыл администрациясенә (алар Большие Поляныга керәләр), районга барып житv бик авыр, юл юк. Исса елгасы аша жәяvлеләр очен асылмалы кvпер бар һәм жәй коне авылга туфрак юл белән барып житәргә момкин; ул кvрше Адашево авылы фермерынын хужалыгы билгеләнешендәге жирләре буенча уза. Әмма кыш коне юл чатындагы торак пунктка барып житv проблемалы була. Авыл халкы елдан-ел vз проблемалары белән торле инстанцияләргә йори. Ә муниципаль-ара әһәмияттәге юлнын транспорт белән тәэмин ителеше проблемасын тvбән сулы кvпер хәл итә алыр иде. Парламентарий гражданнарнын социаль әһәмиятле морәжәгатен аерым контрольгә алды, халыкка морәжәгать астында имзалар жыярга тәкъдим итте, Мордовиянен Транспорт һәм юл хужалыгы буенча дәvләт комитетына депутат соравы әзерләнәчәк.
Морәжәгать иткән барлык гражданнарга да сораулар хәл ителve турында хәбәр ителәчәк.